**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Урсаевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального**
**района**

ул. Центральная, д. 65, село Урсаево,
Азнакаевского муниципального района, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл**
**җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урам, 65, Урсай авылы
Азнакай муниципаль районы, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Меслим торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 23.11.2020 ел Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мәслим торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Меслим пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 23 ноябрь 2019 ел 11.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Мәслим авылы, Гафури ур. , 31 йорт, Мәслим авыл мәдәният йорты янында ;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 14 дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Мәслим торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Мәслим торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Беек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, кендезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә, 2 теркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 175 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Такташ урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр ечен түләү)

- Меслим авылында урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү һәм карап тоту (лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)

- Меслим авылы зиратына контейнерлар алу; контейнер мәйданчыклары урнаштыру ( коймалау өчен материал алу, коймаларны ясау һәм урнаштыру, җирлеген ясау);

- карны механикалаштырылган рәвештә чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү;

- Меслим авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау ( артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу, материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр башкару, эчәргә яраклы суга анализ үткәрү)

- бәйрәм чараларын үткәрү ("Җиңү көне", "Сабантуй", "Яңа ел " бүләк һәм сувенирлар сатып алу)")

- Мөслим авылында Такташ урамында кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мөслим авылы, Такташа ур., 10 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән кеннән үз кеченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: З.Х.Рахимьянова

УРСАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1643002416
КПП 164301001